АГЕНТСТВО ИНВЕСТИЦИОННОГО РАЗВИТИЯ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ИНВЕСТИЦИОН ҮСЕШ АГЕНТЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

«17» апрель 2023 ел № 11

Татарстан Республикасының инвестицион үсеш агентлыгына кергән ришвәтчелек юнәлештәге фактлар буенча гражданнар мөрәҗәгатьләре белән эшләү Тәртибе турында

«Татарстан Республикасында гражданнар мөрәҗәгатьләре турында» 2003 елның 12 маендагы № 16-ЗРТ Татарстан Республикасы Законының 21 статьясы нигезендә боеру:

1. Татарстан Республикасының инвестицион үсеш агентлыгына кергән ришвәтчелек юнәлештәге фактлар буенча гражданнар мөрәҗәгатьләре белән эшләү Тәртибен расларга.
2. Билгеләргә:

Татарстан Республикасының инвестицион үсеш агентлыгында хокукый һәм кадрлар белән тәэмин итү бүлеге катнашында ришвәтчелек һәм башка хокук бозуларны профилактикалау эше өчен җаваплы зат гражданнарның ришвәтчелек юнәлештәге мөрәҗәгатьләрен карауны гамәлгә ашыруны;

ришвәтчелек юнәлештәге фактлар буенча гражданнар мөрәҗәгатьләре белән эшләүче вазыйфаи затлар Россия Федерациясе законнары нигезендә хезмәт мәгълүматларын һәм конфиденциаль характердагы мәгълүматларны саклау өчен җаваплы булуны.

3. «Татарстан Республикасының инвестицион үсеш агентлыгына кергән ришвәтчелек юнәлештәге фактлар буенча гражданнар мөрәҗәгатьләре белән эшләү Тәртибен раслау турында» Татарстан Республикасының инвестицион үсеш агентлыгының 19.04.2019 № 20 боерыгы үз көчен югалткан дип тануны.
4. Әлеге Боерыкның үтәлешен контрольдә тотам.

Җитәкче Т.И. Миңнуллина

Татарстан Республикасының
инвестицион үсеш агентлыгы
боерыгы белән расланган
__17.04.2023___________ №_11___

Татарстан Республикасының инвестицион үсеш агентлыгына кергән ришвәтчелек юнәлештәге фактлар буенча гражданнар мөрәҗәгатьләре белән эшләү
Тәртибе

1. Әлеге Тәртип «Татарстан Республикасында гражданнарның мөрәҗәгатьләре турында» 2003 елның 12 маендагы № 16-ЗРТ Татарстан Республикасы Законының 21 статьясын үтәү максатыннан эшләнгән һәм Татарстан Республикасының инвестицион үсеш агентлыгына (алга таба – Агентлыкка) кергән ришвәтчелек юнәлешендәге фактлар буенча гражданнарның мөрәҗәгатьләрен карау үзенчәлекләрен билгели, алар үзләрендә ришвәтчелек һәм акча алу фактлары, гражданнарның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен кысу, хезмәт тәртибенә карата таләпләрне бозу, шулай ук Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре (алга таба – хезмәткәрләр), шулай ук дәүләт вазыйфалары булмаган вазыйфаларны биләүче хезмәткәрләр һәм техник тәэмин итүне һәм хезмәт күрсәтүне гамәлгә ашыручылар (алга таба — эшчеләр) тарафыннан башкарылган хезмәт урыныннан файдалану билгеләрен (алга таба — мөрәҗәгать) үз эченә алган башка гамәлләр турында белешмәләрне кертә. «Россия Федерациясе гражданнары мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында» 2006 елның 2 маендагы № 59-ФЗ Федераль законның 8 статьясындагы 3 өлешенә туры килеп, мөрәҗәгатьләрдә куелган мәсьәләләрне хәл итү компетенциясенә кергән тиешле органга яки тиешле вазыйфаи затка башка затларга карата шундый ук фактлар турында мәгълүматлар булган мөрәҗәгать җибәрелергә тиеш.

2. Мөрәҗәгать «Россия Федерациясе гражданнары мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында»гы Федераль закон нигезендә билгеләнгән тәртиптә һәм срокларда теркәлә һәм карала.

Әгәр мөрәҗәгатьтә әзерләнгән, башкарыла торган яки башкарылган законсыз гамәл турында, шулай ук аны әзерләгән, башкара торган яки башкарган кеше турында мәгълүматлар булса, мөрәҗәгать компетенциясенә туры килгән хокук саклау органнарына җибәрелергә тиеш.

3. Хокукый һәм кадрлар белән тәэмин итү бүлеге тарафыннан бер эш көне дәвамында, мөрәҗәгатьне теркәгән көннән башлап, «Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәте турында» 2004 елның 27 июлендәге № 79-ФЗ Федераль закон белән билгеләнгән тәртиптә хезмәткәргә карата хезмәт тикшерүе үткәрү инициативасы куела (хезмәткәрдән язма аңлатмалар сорала).

4. Комиссия нәтиҗәсен алганнан соң өч эш көне эчендә хезмәт тикшерүе үткәргән комиссия нәтиҗәсе нигезендә ришвәтчелек билгеләре булу турындагы фактлар расланган очракта, Агентлык җитәкчесе (аның вазыйфаларын башкаручы) Татарстан Республикасының инвестицион үсеш агентлыгының дәүләт граждан

хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча комиссиясенә тәкъдимнәр кертә. Хезмәткәргә карата тиешле фактлар расланган очракта, аның язма аңлатмаларын анализлаудан чыгып, аңа карата Россия Федерациясенең норматив хокукый актларында каралган җаваплылык чараларын куллану мәсьәләсе хәл ителә.

Хезмәт тикшерүе, шулай ук хезмәткәрнең язма аңлатмаларын анализлау нәтиҗәләре буенча әзерләнә торган, башкарыла торган яки башкарылган законсыз гамәл турында, шулай ук аны әзерләүче, башкаручы яки башкарган зат турында билгеле булган очракта, тиешле мәгълүмат комиссия нәтиҗәсен алганнан соң өч эш көне эчендә компетенциясенә туры килгән хокук саклау органнарына җибәрелергә тиеш.

5. Мөрәҗәгать җибәргән гражданга җавапны әзерләү Агентлыкта ришвәтчелек һәм башка хокук бозуларны профилактикалау өчен җаваплы зат тарафыннан башкарыла.

6. Әгәр мөрәҗәгатьтә Агентлыкта ришвәтчелек һәм башка хокук бозуларны профилактикалау эше өчен җаваплы затка карата ришвәтчелек юнәлештәге фактлары турында мәгълүмат булса, соңгысына, бер эш көне дәвамында әлеге мөрәҗәгатьне караганда мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча чаралар күрергә кирәк, шул ук вакытта үзенең туры җитәкчесенә һәм Татарстан Республикасының инвестицион үсеш агентлыгында дәүләт хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча комиссиягә хәбәр итәргә кирәк.